СОВЕТ ДЮСЬМЕТЬЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Молодежная, д.17, с. Дюсьметьево,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 4221750

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ДҮСМӘТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Яшьләр ур., 17 нче йорт, Дүсмәт авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422150

тел.(факс): (85563) 2-55-19; e-mail:Dusm.Mam@tatar.ru, www: mamadysh.tatarstan.ru

Карар
“20” ноябрь, 2018ел.

Решение
№4-38

## 2018 елның 18 ноябрендә үткәрелгән җирле референдумда кабул ителгән карарны теркәү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 12.06.2002 ел, № 67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 22, 56 статьялары, «җирле референдум турында» 2004 елның 24 апрелендәге 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы нигезендә, 2018 елның 18 ноябрендә үткәрелгән җирле референдум нәтиҗәләре нигезендә бирелгән сораулга:

«2019 елда Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Дүсмәт авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган, 1 һәм 2 төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләр ветераннары, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, күп балалы гаиләләрдән, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә чакырылган гражданнардан кала, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә 400 сум күләмендә үзара салым кертергә риза буласызмы?:

1. Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- Комазан Башы торак пунктындагы Үзәк урамына, Дүсмәт торак пунктының Яшьләр урамына, Акман торак пунктының Ленин урамына, Иске Комазан торак пунктының Купер урамына вак таш җәеп ремонтлау;
- җирлек торак пунктларында җирле әһәмияттәге юлларны тигезләү һәм кардан чистарту.

«ӘЙЕ» «ЮК»

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Дүсмәт авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы территориаль сайлау комиссиясенең 2018 елның 19 ноябрендәге 903 номерлы «Татарстан Республикасы

Мамадыш муниципаль районы Дүсмәт авыл җирлеге территориясендә җирле референдум нәтиҗәләре турында»карарын теркәргә.

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

Мамадыш муниципаль районы
Дүсмәт авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе

СОВЕТ ДЮСЬМЕТЬЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

О.Н.Павлов